Республика Татарстан
Совет Старо-Имянского сельского поселения
Сармановского муниципального района
423373, с. Старый Имян,
ул. М. Вахитова,36 в

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Иске Имән авыл жирлеге Советы
423373, Иске Имән авылы,
М. Вахитов урамы, 36 в йорт

КАРАР | КАРАР

2 ноябрь 2015 ел | №9

**Сарман муниципаль районы «Иске Имән авыл жирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктату турында**

Россия Федерациясенең «2016 елга Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары проектларын төзү һәм раслау үзенчәлекләре турында " 30.09.2015 №273-ФЗ Федераль законы нигезендә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында»Федераль законның 3 статьясының үз көчен югалтуын тану хакында, Сарман муниципаль районы Советынын " 2016 елга бюджет проектын төзү, раслау үзенчәлекләре турында" 2015 елның 16 октябрендә кабул ителгән 13 номерлы карар нигезендә,

1. План чорына жирлек бюджеты проектын (жирлек бюджеты турында карар проектын) төзү һәм раслауга карата, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органына Сарман муниципаль районы Советы карары проекты белән бер үк вакытта план чорына документлар һәм материаллар (социаль-икътисадый үсеш фаразыннан тыш, бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләреннән тыш) бирүне Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы " Иске Имән авыл жирлеге»муниципаль берәмлеге Уставының 70 статьясы 2016 елнын 1 гыйнварына кадәр гамәлдә булуын туктатып торырга.
2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Иске Имән авыл жирлеге рәисе Р.Ә.Исламова